**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОКУТУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Свежухина, дом 34, с.Старые Кутуши, 423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ КОТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Свежухин урамы, 34нче йорт, Иске Котыш авылы, 423116

Тел(84396)2-72-47
Skut.Cmn2@tatar.ru

30.09.2021ел № 33

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге 119 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге 119 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 п. 14 абзацын бәян итәргә «Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр тапшырыла, ул салым чоры булып тора, шуннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла. Сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Иске Котыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.К.Митякин